СОВЕТ
ТАШКИЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,
Арский муниципальный район, 422039

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАШКИЧҮ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,
Арча муниципаль районы, 422039

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

**Ташкичү авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**«11» сентябрь 2020 ел** **№54**

**Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә һәм пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр акчалата түләү турында**

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатыннан "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы Федераль закон, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында"2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2009 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында кодексы," Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" 2018 елның 28 мартындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 1 нче кушымта итеп бирелгән Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими рәвештә башкаручы затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү турында Нигезләмәне расларга.

2. 2 нче кушымта итеп бирелгән Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү турында Нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карар нигезендә социаль ярдәм чараларын күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чаралары турында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматларга туры китереп мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

4. Әлеге карарда күрсәтелгән категорияләрдәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматларга туры китереп, ЕГИССОны куллану юлы белән алынырга мөмкин.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http:arsk.tatarstan.ru).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Ф.Х.Фәйзуллин

*Арча муниципаль*
*районы* Ташкичү *авыл җирлегенең*
*“11”сентябрь 2020 ел, №54*
*карарына*
*1 нче кушымта*

Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими рәвештә башкаручы затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү турында Нигезләмә

1. Әлеге Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны даими рәвештә башкаручы затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү турында Нигезләмә (алга таба - бер тапкыр түләү) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында»2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде.

2. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә пенсиягә өстәмә хокук булганда, вазыйфадан (шул исәптән вакытыннан алда) азат ителгәндә, биләгән вазыйфасы буенча билгеләнгән айлык түләүнең ун тапкыры күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү түләнә.

3. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларга бер тапкыр бирелә торган түләү түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

1) Татарстан Республикасында даими нигездә муниципаль вазыйфа, шул исәптән депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфаларын 1995 елның 5 мартыннан 2006 елның 1 гыйнварына кадәр кимендә биш ел биләгәндә яисә җирле үзидарә органы вәкаләтләренең тулы срогы кимендә өч ел булганда;

2) муниципаль вазыйфаны 2006 елның 1 гыйнварына һәм (яки) соңрак биләгәндә;

3) "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" Федераль закон) нигезендә картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясе билгеләнгәндә.

4. Бер тапкыр бирелә торган түләү вәкаләтләр туктатылу (шул исәптән вакытыннан алда) бәйле рәвештә эштән азат ителгән очракта түләнми:

а) ышанычны югалту;

б) вазыйфадан ваз кичү;

в) отставкага җибәрелү;

г) судның гаепләү карары законлы көченә керү;

д) сайлаучылар фикере;

е) федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү, йөкләмәләрне үтәмәү;

ж) муниципаль вазыйфа биләүгә комачаулаучы хәлләр ачыклану;

з) муниципаль вазыйфаны биләү белән бәйле вәкаләтләрне үтәмәү яки тиешенчә башкармау;

и) сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарны бозган өчен административ җәза билгеләү турында суд карары (карарлары) законлы көченә керү.

5. Муниципаль вазыйфа биләүче затка, пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында карар Ташкичү авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә.

6. Бер тапкыр бирелә торган түләү Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы тарафыннан муниципаль вазыйфаны биләүче затка пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында карар кабул ителгәннән соң бер айдан да соңга калмыйча түләнә.

7. Бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен билгеләү өчен Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә түбәндәге документларны тапшыра:

- даими нигездә сайланулы вазыйфаны биләп торучы затның пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында гаризасы;

пенсиягә чыгу сәбәпле, муниципаль вазыйфа биләүче затка бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында карар;

муниципаль вазыйфаны биләүче затка айлык акчалата түләү турында белешмә;

җирле үзидарә органы җитәкчесе һәм кадрлар хезмәте тарафыннан расланган муниципаль һәм (яки) дәүләт вазыйфаларын, дәүләт граждан хезмәте һәм (яки) муниципаль хезмәт стажы (стажы) биләп торуның гомуми вакыты (стажы) турында белешмә;

хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрнең күчермәләре (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66_1 статьясы) һәм җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте раслаган хәрби билет күчермәләре;

8. Бер тапкыр бирелә торган түләү бер тапкыр түләнә. Муниципаль вазыйфаны биләгәндә яки гражданны пенсиягә чыкканнан соң һәм муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен туктатканда яисә муниципаль хезмәттән азат ителгәндә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләү кабат түләнми.

*Арча муниципаль районы* Ташкичү *авыл җирлегенең “11” сентябрь 2020 ел, №54 карарына 2 нче кушымта*

Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү турында
Нигезләмә

1. Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу белән бәйле рәвештә бер тапкыр акчалата түләү турында Нигезләмә 2009 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында кодексының 31 статьясы нигезендә эшләнде.

2. Муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, муниципаль хезмәт стажы булган очракта, аның эштән азат ителгән көнгә биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча айлык түләүнең биш тапкыры күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү түләнә. Муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәткәрне муниципаль хезмәттән азат иткән көнгә билгеләнә.

3. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу дигәндә, картлык буенча хезмәт пенсиясе алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч яисә «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә инвалидлык буенча пенсия билгеләгәндә, муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле эштән азат ителүдән тыш, һәм тиешле еллар эшләгән өчен пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда, муниципаль хезмәттән азат ителү аңлашыла.

4. Бер тапкыр бирелә торган акчалат атүләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акчалата керем составына түбәндәгеләр кертелә:

- вазыйфаи оклад;
- класс чины өчен вазыйфаи окладка өстәмә;
- еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүнең 1/12 күләме;
- тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка өстәмә;
- вазыйфаи окладның 50 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата түләү;
- дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;
- муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнгә кадәр алты айдан да ким булмаган күләмдә муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;
- хезмәт көне нормалаштырылмаган шартларда эшләгән өчен компенсация түләүләре;
- профильле гыйльми дәрәҗә өчен вазыйфаи окладка өстәмә.

5. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турындагы карар эш бирүче (яллаучы вәкиле) тарафыннан кабул ителә, тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү турында карар кабул ителү белән бер үк вакытта рәсмиләштерелә.

6. Бер тапкыр бирелә торган түләү муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгәнче хезмәт итә торган органның эш бирүче (яллаучы вәкиле) тарафыннан түләнә.

7. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган түләү бер тапкыр түләнә. Гражданин тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыккач һәм аннан соң муниципаль хезмәт туктатылгач, муниципаль хезмәткә бер тапкыр бирелә торган тәләү кабат түләнми.

8. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр эштән киткәнче 30 календарь көн эчендә җирле үзидарә органнарына бер тапкыр бирелә торган түләү күләмен билгеләү өчен, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә (алга таба - финанс-бюджет палатасы) түбәндәге документларны тапшыра:

8.1.пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү турында муниципаль хезмәткәр гаризасы;

8.2. муниципаль хезмәткәргә айлык акчалата түләүләр турында белешмә;

8.3. муниципаль хезмәттәге эш стажы турында җитәкче һәм кадрлар хезмәте раслаган белешмә;

8.4. хезмәт кенәгәсенең һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрнең күчермәләре (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66_1 статьясы) һәм кадрлар хезмәте раслаган хәрби билет күчермәләре;

8.5. класс чины бирү, муниципаль хезмәткәрнең айлык акчалата кереме составына керүче вазыйфаи окладка өстәмәләр билгеләү турында күрсәтмәләрдән өземтә;

8.6. дисциплинар җәза булмау турында белешмә.

9. Бер тапкыр бирелә торган тәләү түләнми:

9.1. эштән азат ителгән вакытка дисциплинар җәзасы алынмаган муниципаль хезмәткәргә;

9.2. дәүләт граждан хезмәте турындагы законнар нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләү түләнгән муниципаль хезмәткәргә.

10. Бер тапкыр бирелә торган түләү хезмәт кенәгәсенә билге куеп түләнә.

*Арча район Советының 2014 елның 6 маендагы 272 номерлы карары белән расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә кушымта*

**Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган бүләкләү билгеләү өчен муниципаль хезмәт СТАЖЫ**

| Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү елы | Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган түләү билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажы |
|---|---|
| 2017 | 15 ел 6 ай |
| 2018 | 16 ел |
| 2019 | 16 ел 6 ай |
| 2020 | 17 ел |
| 2021 | 17 ел 6 ай |
| 2022 | 18 ел |
| 2023 | 18 ел 6 ай |
| 2024 | 19 ел |
| 2025 | 19 ел 6 ай |
| 2026 һәм аннан соңгы еллар | 20 ел |